СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

10.10.2022 № 2419

На №__________от______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруы җирле нормативларын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруы җирле нормативларын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруы җирле нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 23 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының шәһәр төзелеше проектлаштыруы җирле нормативларын раслау турында карарны Федераль дәүләт территориаль планлаштыру мәгълүмат системасының рәсми сайтында (fgistp.economy.gov.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Ф.М. Камаев